КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 март г.Казань № 268

Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 8 мартындагы 46-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 31 декабренә кадәрге чорда «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак, түбәндәге факторларның барысы да булганда, Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру рөхсәт ителә дип билгеләргә.

сатып алуны гамәлгә ашыру шартлары һәм икътисадый вәзгыять, шул исәптән чит ил валютасы курсының үзгәрүчәнлеге, чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмаларның дусларча булмаган гамәлләре белән характерлана торган икътисадый вәзгыять арасындагы сәбәп-нәтиҗә элемтәсен билгеләү;

сатып алуны гамәлгә ашыру сроклылыгы.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы иктисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт

ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статья-сындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия составын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 24 март, 268 нче
карары белән расланды

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашыру
тәртибе

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карарының 1 пункты нигезендә бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырган очракта, Татарстан Республикасы заказчылары:

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы икътисады тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Ведомствоара комиссия) белән бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерә;

1.2. Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү турында Ведомствоара комиссия бәяләмәсен алган көннән өч эш көне эчендә бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзи;

1.3. Контракт төзелгән көннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзү турында Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә хәбәрнамә җибәрә. Бу хәбәрнамәгә төзелгән контрактның күчермәсе һәм контракт төзүнең нигезләве теркәлә.

2. Заказчы тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдим бюджет акчасы белән баш эш итүче адресына кертелә (булганда).

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдимнәр Ведомствоара комиссия секретаре адресына кертелә.

4. Бу Тәртипнең 2 һәм 3 пунктлары нигезендә җибәрелә торган бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдимдә күздә тотылган һәр тәэмин итеп торучыга (подрядчыга, башкаручыга) һәм һәр сатып алуга карата бу Тәртипнең кушымтасында күрсәтелгән мәгълүмат булырга тиеш.

5. Заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүченең бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдим Ведомствоара комиссия утырышында карап тикшерелергә тиеш.

6. Тәкъдимне карап тикшерү йомгаклары буенча Ведомствоара комиссия җитәкчесе тарафыннан заказчыга бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләве турында бәяләмә бирелә.

7. Бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) белән контракт төзү турындагы карар заказчы тарафыннан бары Ведомствоара комиссия утырышында бәяләмәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләве турында бәяләмә алынганнан соң кабул ителә.

8. Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашырганда төзелгән контракт турында мәгълүмат «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә заказчылар белән төзелгән контрактлар реестрында урнаштырыла.

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдим составында җибәрелә торган мәгълүмат исемлеге

Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдимдә күздә тотылган һәр тәэмин итеп торучыга (подрядчыга, башкаручыга) һәм һәр сатып алуга карата түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) контрактның предметы һәм сатып алу объектының тасвирламасы; ул сатып алу объектының функциональ, техник һәм сыйфат ягыннан, эксплуатация тасвирламаларын (кирәк булганда) үз эченә ала;

б) сатып алуны гамәлгә ашыру шартлары һәм икътисадый вәзгыять, шул исәптән чит ил валютасы курсының үзгәрүчәнлеге, чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмаларның дусларча булмаган гамәлләре белән характерлана торган икътисадый вәзгыять арасындагы сәбәп-нәтиҗә элемтәсе булуны нигезләү һәм сатып алуны гамәлгә ашыру сроклылыгын икътисадый һәм (яки) технологик нигезләү;

в) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы нигезендә әзерләнгән һәм заказчы тарафыннан имзаланган бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясен нигезләү;

г) заказчы исеме;

д) күздә тотылган бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) турында мәгълүмат (аның исемен, салым түләүченең тәңгәлләштерү номерын һәм мондый тәэмин итеп торучыны (подрядчыны, башкаручыны) сайлап алу нигезләвен кертеп);

е) бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алуны гамәлгә ашыруның күздә тотыла торган срогын нигезләү;

ж) заказчы тарафыннан күздә тотылган бердәнбер тәэмин итеп торучының (подрядчы, башкаручының) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы таләпләренә туры килү-килмәвенә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре;

з) күздә тотылган бердәнбер тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) тарафыннан контракт буенча үз йөкләмәләрен шәхсән яки аны үтәү өчен субподрядчылар, башкарудашчыларны җәлеп итеп башкару турында мәгълүмат һәм аларны җәлеп итү кирәклеген нигезләү, шулай ук мондый контракт буенча бу тәэмин итеп торучы (подрядчы, башкаручы) тарафыннан үз йөкләмәләрен шәхсән, аны үтәү өчен субподрядчылар, башкарудашчылар җәлеп ителгән очракта, аның белән төзелә торган контракт бәясеннән процент рәвешендә билгеләнгән үтәү күләменә карата таләп;

и) контракт этапларын билгеләү турында мәгълүмат (кирәк булганда);

к) аванс күләме турында (контрактта аванс бирү каралган очракта), контрактның һәр үтәлеше этабына карата аванс күләме турында (контрактта аның үтәү этаплары каралган очракта) мәгълүмат;

л) контрактның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләп билгеләү турында мәгълүмат яки мондый таләп билгеләүнең максатка ярашлы булмавын нигезләү; гарантия йөкләмәләрен тәэмин итүгә карата таләп билгеләү турында мәгълүмат яки мондый таләпләр билгеләүнең максатка ярашлы булмавын нигезләү;

м) контракт буенча аванска һәм (яки) контрактка карата казначылык тикшерүен тәэмин итү турында мәгълүмат;

н) сатып алуны финанслау чыганаклары һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, заказчыга җиткерелгән финанслау лимитлары турында мәгълүмат;

о) тәэмин итеп торучының (подрядчы, башкаручының) Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча недоимкасы булмавын раслау;

п) күздә тотылган бердәнбер тәэмин итеп торучыны сайлап алуны нигезләү (кайтарту срогы, иң түбән бәясе һәм башка шартлар нигезендә).

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 24 март, 268 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы иктисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы иктисадын тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия коллегиаль орган булып тора һәм «Дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән очракларда бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен карап тикшерү һәм килештерү максатларында төзелә.

## II. Ведомствоара комиссия функцияләре

2. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны башкару өчен заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүченең бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдимен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 24 март, 268 нче карары белән расланган «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның

93 статьясындагы 1 өлешендә каралган очракларга өстәмә буларак Татарстан Республикасы заказчылары тарафыннан бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны гамәлгә ашыру тәртибенә кушымтада күздә тотылган һәм үзенә тапшырылган мәгълүматны карап тикшерә.

## III. Ведомствоара комиссиянең хокуклары

3. Ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасы заказчыларыннан үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат, документлар, материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

Ведомствоара комиссия утырышларында катнашу өчен дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкилләрен һәм белгечләрен, сатып алуны гамәлгә ашырырга планлаштыручы заказчы вәкилен җәлеп итәргә.

## IV. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру

4.1. Ведомствоара комиссия составына Ведомствоара комиссия җитәкчесе, аның урынбасары, секретаре, әгъзалары керә. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.2. Ведомствоара комиссия җитәкчесе:

аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

чираттагы утырышның датасын билгели;

чираттагы утырышның көн тәртибен раслый;

утырышларда рәислек итә;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыруны гомуми контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.3. Ведомствоара комиссия җитәкчесе вакытлыча булмаган чорда аның вазыйфаларын җитәкче урынбасары башкара.

4.4. Ведомствоара комиссия секретаре:

аның утырышына материаллар әзерләүне тәэмин итә;

ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Ведомствоара комиссия әгъзаларына чираттагы утырыш турында хәбәр итә һәм аларга утырышта каралачак материалларны җибәрә;

Ведомствоара комиссия утырышында аның тәкъдимен карап тикшерү йомгаклары буенча бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү (килештермәү) турындагы бәяләмәләрне заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүчегә җибәрүне тәэмин итә.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышлары кирәк булуга карап, әмма заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүченең бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдиме

булганда айга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Шул ук вакытта Ведомствоара комиссия утырышы аның җитәкчесе тарафыннан заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүченең бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыруны нигезләү турындагы тәкъдиме кергәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча билгеләнә.

4.6. Әгәр Ведомствоара комиссия утырышында әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

4.7. Ведомствоара комиссия карары, Ведомствоара комиссия утырышында катнашмаган әгъзаларның язма фикерләрен исәпкә алып, Ведомствоара комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү (килештермәү) турында бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, җитәкче яки аның утырышта рәислек итүче урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора. Карар шулай ук читтән торып тавыш бирү юлы белән (сорау алу юлы белән) кабул ителергә мөмкин.

4.8. Ведомствоара комиссия утырышында Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе вәкиле катнашкан очракта, тавыш бирү процессында аның тарафыннан кабул итә торган карар хәлиткеч (вето хокукы) булып тора.

4.9. Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыруны нигезләвен килештерү (килештермәү) турындагы бәяләмә, Ведомствоара комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән соң килә торган ике эш көненнән дә соңга калмыйча, мондый сатып алуны гамәлгә ашыру турында тәкъдим керткән заказчы/бюджет акчасы белән баш эш итүчегә җибәрелә.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 24 март, 268 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, б-387 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы иктисадының тотрыклы үсешен тәэмин итүнең төп чаралары планын тормышка ашыру буенча оператив штабның Бердәнбер тәэмин итеп торучыдан (подрядчыдан, башкаручыдан) дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны гамәлгә ашыру нигезләвен килештерү буенча ведомствоара комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Ведомствоара комиссия җитәкчесе |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры, Ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары |
| Сабиров Руслан Наил улы | Ведомствоара комиссия секретаре |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Кудрявцева Алевтина Николаевна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры |

| | |
|---|---|
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанслар министрының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Яфизов Алмаз Альберт улы | Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча). |